ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘРКӘТӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ,
ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а”

тел.+7(84396)
2-64 -66
тел./факс
+7(84396) 2-64-66

423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ,
УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

25.05.2023 ел №84

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүеннән соң өч еллык срокның тәмамлануы, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алуга хокуклы булмаса яки варисларның барсы да мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәсә, яки варисларның барысы да мирас алудан баш тартса һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

3) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

ТР Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының 2022 елның 23 ноябрендәге № 69 «Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» карары үз көчен югалткан дип саналырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.М.Сибгатуллин